**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» 04 2016 № 217

Аксубаево

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2013 елның 04 апрелендәге 111 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

1.1. «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча торак сатып алуга (төзелешкә) социаль түләү алуга хокук турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта).

1.2. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Торак урыннарына мохтаҗ аерым категориядәге гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта)

1.4. Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм аларга тиңләштерелгән затларга радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга һәм дәүләт торак сертификатын исәпкә кую һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта).

1.5. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектәге торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).
1.6. Урынны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле торак урын дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).
1.7. Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта).
1.8. Социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлекләренә кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты һәм авыл җирендә торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклык бирү (8 нче кушымта).
1.9. Торак урынны яңадан урнаштыруга һәм (яисә) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (9 нчы кушымта).
1.10. Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (10 нчы кушымта).
1.11. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (11 нче кушымта).
1.12. Җир эшләрен җитештерүгә ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты. (12 нче кушымта).
1.13. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (13 нче кушымта).
1.14.Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (14 нче кушымта).
1.15. Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр схемасын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (15 нче кушымта).
1.16. Агач һәм куакларны кисүгә, кронировкалауга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (16 нчы кушымта).
1.17. Ана (гаилә) капиталы чараларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган ИЖС объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслый торган документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (17 нче кушымта).
1.18. Күпфатирлы торак йортның беренче катында урнашкан фатирда балкон (лоджия) төзелешен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (18 нче кушымта).
1.19. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең җирлекнең генераль планыннан (19 нчы кушымта) өземтә әзерләү буенча административ регламенты.
1. 20. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (20 нче кушымта).

1.21. Җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (21 нче кушымта)
1.22. Шәхси яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башка категориягә күчерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (22 нче кушымта)
1.23. Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (23-нче кушымта).
1.24. Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (24 нче кушымта).
1.25. васыятьләр таныклыгы буенча һәм ышанычнамәләр таныклыгы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (25 нче кушымта).
1.26. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (26 нчы кушымта).
1.27. Архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләре бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (27 нче кушымта).
1.28. Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен кулланучыга архив документларын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (28 нче кушымта).
1.29. Юридик затларга архивлар эшендә методик һәм практик ярдәм күрсәтү һәм эш башкаруда документлар оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (29 нчы кушымта).
1.30. Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (30 нчы кушымта).
1.31. Ликвидацияләнә торган оешмаларның шәхси составы буенча документларны муниципаль архивка саклауга алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (31 нче кушымта).

2. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 августындагы 291 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга

3. Кадрлар бүлегенә өч эш көне эчендә Аксубай муниципаль районы буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасары И.И. Муратшинга йөкләргә.

Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Ф. Горбунов